ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Постановление Карар

2025 елның 20 нче гыйнвары №2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 декабрендәге 22 нче номерлы карары белән расланган 2020-2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы РФ Шәһәр төзелеше кодексы, РФ Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында»2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 декабрендәге 22 нче номерлы карары белән расланган 2020-2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәрешләр кертергә:

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**2.7 Җәяүлеләр, велосипедта йөрү һәм хәрәкәт итү өчен индивидуаль мобиль хәрәкәт итү чарасын кулланучы затларның шартларына характеристика.**

Туктар-Урдаласы авыл җирлеге территориясендә велосипед хәрәкәте һәм индивидуаль мобильлек чараларын хәрәкәт итү өчен файдаланучы затлар, оешкан формаларда күрсәтелмәгән һәм аерым инфраструктура юк.».

2. Әлеге карарның 1 пунктында каралган үзгәрешне территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертергә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында

урамы,31 йорты, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында(https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Ә.Әхмәтова